**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 11 июль № 473

г. Казань

Кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештырганда хезмәттәшлек итү регламентын раслау турында

Татарстан Республикасында кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештырганда хезмәттәшлек итү регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

кеше күп катнаша торган чараларны үткәргәндә Регламентка таянып эш итәргә;

кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештыруны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

кеше күп катнаша торган чараларны үткәргәндә Регламентка таянып эш итәргә;

кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештыруны җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре, оешмаларның үз акчалары чикләрендә гамәлгә ашырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 11 июль, 473 нче карары белән расланды

**Кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештырганда хезмәттәшлек итү регламенты**

1. Бу Регламент, Татарстан Республикасында кеше күп катнаша торган чаралар үткәргәндә, кеше күп катнаша торган чараны оештыручы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм ашыгыч медицина ярдәменең күчмә бригадалары һәм (яки) Республика һәлакәтләр медицинасы үзәгенең махсуслаштырылган бригадалары (алга таба – күчмә бригадалар) кизү торуын тәэмин итү буенча медицина оешмаларының үзара хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

2. Әлеге Регламентта түбәндәге төп төшенчәләр файдаланыла:

кеше күп катнаша торган чара (алга таба – чара) – күп гражданнар катанаша торган мәдәни-агарту, театр-тамаша, спорт яки башка характердагы гавами чара;

чараны оештыручы – чараны әзерләүне һәм үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы яки оешма;

чарада катнашучылар – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы, оешмалар вәкилләре, кунаклар, артистлар, спортчылар, тамашачылар, шулай ук чараны әзерләүдә һәм үткәрүдә турыдан-туры катнаша торган башка физик затлар.

3. Чараны оештыручы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына чараның программасын, чарада катнашучыларның күздә тотылган саны һәм чара үткәрергә планлаштырыла торган территория турындагы мәгълүматны чараны үткәрү көненә кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрүне;

чарада катнашучыларның фаразлана торган санын, чараны үткәрергә планлаштырыла торган территориянең зурлыгын һәм үзенчәлекләрен исәпкә алып, шулай ук тәкъдим ителә торган чарада катнашучы 4 мең кешегә – кимендә 1 күчмә бригада, чараны трассада үткәргәндә һәр 4 км дистанциягә 1 күчмә бригада исәбеннән чыгып, күчмә бригадаларда ихтыяҗны билгеләүне;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән чараны медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру өчен күчмә бригадалар санын чараны үткәрү көненә кадәр җиде эш көненнән дә соңга калмыйча килештерүне;

медицина оешмасы белән күчмә бригадалар урнашу урыннарын, чараны үткәрү территориясендә урнашкан объектларга керү юлларын һәм медицина эвакуациясен килештерүне;

медицина оешмасы белән билгеләнгән тәртиптә медицина оешмасының әлеге Регламентның 5 нче пунктында күрсәтелгән вазыйфаларын үтәүне күздә тоткан

медицина хезмәтләре күрсәтү (күчмә бригадаларны җәлеп итеп, чараны медицина ягыннан тәэмин итү) турында шартнамә төзүне;

күчмә бригадаларга дислокация урыннарына керергә рөхсәтне, күчмә бригадаларның чараны үткәрү территориясендә урнашкан объектларга киртәләрсез керә алу һәм чараны үткәрү территориясеннән медицина эвакуациясе мөмкинлеген;

чараны үткәрү территориясендә медицина персоналының куркынычсызлыгын.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

чараны оештыручыдан мәгълүмат алган көннән соң дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча чараны медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру өчен күчмә бригадалар санын килештерүне;

чараны оештыручы Татарстан Республикасының дәүләт медицина оешмасы белән медицина хезмәтләре күрсәтү (күчмә бригадаларны җәлеп итеп, чараны медицина ягыннан тәэмин итү) турында шартнамә төзегән очракта, чараны медицина ягыннан тәэмин итүне оештыруны тикшерүдә тотуны.

5. Чараны медицина ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра торган медицина оешмасы медицина хезмәтләре күрсәтү (күчмә бригадаларны җәлеп итеп, чараны медицина ягыннан тәэмин итү) турындагы шартнамә нигезендә түбәндәгеләрне тәэмин итә:

күчмә бригадаларны дислокация урыннарына җибәрүне;

күчмә бригадаларны мобиль элемтә белән тәэмин итүне;

чарада катнашучыларга ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне;

медицина күрсәтмәләре булганда медицина эвакуациясен һәм киткән күчмә бригаданы ул урнашкан урында 30 минут эчендә алыштыруны.

---